КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 март г.Казань № 205

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карары белән расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 сентябрь, 873 нче карары белән (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1281 нче; 2019 ел, 5 февраль, 70 нче; 2019 ел, 22 август, 699 нчы; 2019 ел, 27 декабрь, 1225 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карары белән расланган «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

6 нчы пунктның бишенче абзацында татар текстында «, банкротлык» сүзләрен төшереп калдырырга, «процессында булмаска» сүзләреннән соң «, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәскә, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктның бишенче абзацында татар текстында «, банкротлык» сүзләрен төшереп калдырырга, «процессында булмавын» сүзләреннән соң «, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын» сүзләрен өстәргә;

13 нче пунктта:

өченче абзацта «субсидиядән файдалану һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «өстәмә хисаплылык» сүзләренә алыштырырга, «субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Килешү, аңа карата үзгәрешләр кертүне һәм аны өзүне күздә тота торган өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган бертип формалар нигезендә төзелә.»;

18 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия алучылар, хисап кварталыннан соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны Министрлыкка кертә.»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«үткәрелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм мәдәни-массакүләм чаралар саны.»;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәлелеген бәяләү субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешүдән чыгып гамәлгә ашырыла.»;

20 нче пунктның алтынчы абзацында «нәтиҗәлелек күрсәткечләренә» сүзләрен «субсидияләр бирү нәтиҗәләренә» сүзләренә алыштырырга;

Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20_____ елның «___» ___________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында
хисап

Юридик затның исеме: ________________________

Дәвамлылыгы: ______________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Күрсәт-кеч исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәт-кечнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Юридик зат җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ______________ ___________ __________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У. (булганда)

Үтәүче ______________ ______________ __________________ ______________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу) (телефоны)

20__ ел, «_____» _____________

_____________________________